# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
# ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
# «ИШТИРӘК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»
# МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ

## КАРАР

«13» октябрь 2020 ел Иштирәк авылы № 3/1

«Җирле салымнар буенча недоимканы, пенялар
һәм штрафлар буенча бурычларны түләтүгә өметсез
дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында»

Россия Федерациясе Салым кодексының 59 статьясы 3 пункты, Россия Федераль салым хезмәтенең 2019 елның 2 апрелендәге «Түләтүгә өметсез дип танылган недоимканы һәм пенялар, штрафлар һәм процентлар буенча бурычларны юкка чыгару тәртибен һәм Недоимканы, пенялар, штрафлар һәм процентлар буенча бурычны түләтүгә өметсез дип тану шартларын раслаучы документлар исемлеген раслау турында» ММВ-7-8/164@ номерлы боерыгы нигезендә, муниципаль берәмлек Советы

## КАРАР БИРДЕ:

1. Җирле салымнар һәм җыемнар буенча недоимканы, пенялар һәм штрафлар буенча бурычларны (алга таба – бурыч) түләтүгә һәм юкка чыгаруга өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләргә:

- вафат булган физик затларның бурыч барлыкка килүгә өч елдан артык дата белән җир салымы һәм мөлкәт салымы буенча;

- суд карары яисә Башкарма комитет тарафыннан тапшырылган документлар нигезендә суд тәртибендә хокукка сәләтсез дип танылган психик тайпылышлары булган затларның җир салымы һәм мөлкәт салымы буенча;

- Башкарма комитет тарафыннан бирелгән документлар нигезендә картлар (ветераннар) йортларында яшәүче затларның җир салымы һәм мөлкәт салымы буенча;

- суд карары нигезендә һәм irektән мәхрүм итү урыннарында булган чорга иректән мәхрүм итү урыннарында булган затларның җир салымы һәм мөлкәт салымы буенча;

- бөлгенлек (банкротлык) турында эштә кулланыла торган процедураларда булган салым түләүчеләр буенча бурычлардан тыш, гамәлдән чыгарылган салымнар һәм җыемнар буенча, атап әйткәндә:

а) гражданнардан һәм предприятиеләр, учреждениеләр, оешмалардан милицияне тотуга, территорияләрне төзекләндерүгә, мәгариф ихтыяҗлары өчен максатчан җыемнар;

б) башка җирле салымнар һәм җыемнар;

в) рекламага салым;

г) җир салымы (2006 елның 1 январена кадәр барлыкка килгән йөкләмәләр буенча).

2. Салым түләүченең бурычларын юкка чыгару салым органы тарафыннан әлеге карар һәм салым түләүченең бурычлары турында белешмә нигезендә башкарыла.

3. Әлеге карар бурыч хасил булган мизгелдән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә гамәлдә була.

4. Әлеге карар 2021 елның 1 январеннан, ләкин мәгълүмат стендларында һәм районның рәсми сайтында урнаштырылган көннән бер ай вакыт узганнан соң, үз көченә керә.

5. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны Иштирәк авыл җирлеге Советының законлылык, хокук тәртибе, милли мәсьәләләр һәм халык куркынычсызлыгы буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Иштирәк авыл җирлеге Башлыгы,
Совет Рәисе Г.С Гарифуллина